СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 19 » февраль 2016 ел** **№ 35**

**Арча муниципаль районының һәм аның составына керүче авыл җирлекләренең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында**

«Шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын әзерләү һәм раслау турында» Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 статьясы нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1. Арча муниципаль районының һәм аның составына керә торган авыл җирлекләренең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау тәртибе һәм аларга кушымта нигезендә үзгәрешләр кертү турында нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы рәсми сайтында (https:arsk.tatar.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И. Г. Нуриев

*Арча район Советының*
*«19» февраль 2016ел, №35*
*карарына кушымта*

**Арча муниципаль районының һәм аның составына керүче авыл җирлекләренең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турында Нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге нигезләмә Арча муниципаль районын шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау тәртибен һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгели.

1.2. Арча муниципаль районын шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары (алга таба - җирле нормативлар) муниципаль районның түбәндәге өлкәләргә керә торган җирле әһәмияттәге объектларының: җирлекләрне электр һәм газ белән тәэмин итү, муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, транспорт хезмәте күрсәтү, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәгълүматлаштыру һәм элемтә, мәдәният һәм ял итүне оештыру, социаль тәэмин итү һәм социаль яклау, физик культура һәм массакүләм спорт, көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм эшкәртү, җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү, муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле башка өлкәләр; мондый объектларның муниципаль район өчен мөмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләрен билгели.

1.3. Җирле нормативларда кеше тормышының уңайлы шартларын тәэмин итүнең минималь исәпләү күрсәткечләре, Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларында булган кеше тормышының уңайлы шартларын тәэмин итүнең исәп-хисап күрсәткечләре белән чагыштырганда, түбәнрәк була алмый.

**2. Арча муниципаль районы шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау тәртибе**

2.1. Җирле нормативларны әзерләү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Җирле нормативлар проектын әзерләү турындагы карарда түбәндәгеләр билгеләнә:

- җирле нормативлар проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә;
- җирле нормативлар проектын әзерләү сроклары;
- кызыксынучы затларның тәкъдимнәрен җирле нормативлар проекты буенча җибәрү һәм карау тәртибе;
- җирле нормативларны әзерләү эшләрен оештыруның башка мәсьәләләре.

Җирле нормативлар проектын әзерләү турындагы карары белән җирле нормативларны әзерләүгә техник бирем раслана.

2.3. Җирле нормативлар проектын әзерләү турындагы карар кабул ителгән көннән алып Арча муниципаль районының "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш.

2.4. Җирле нормативларны әзерләү, җирле нормативларга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрне Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар кертергә хокуклы.

2.5. Җирле нормативларны әзерләү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, норматив техник документлар, Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары нигезендә түбәндәгеләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла:

- Арча муниципаль районы территориясендә халыкның социаль-демографик составы һәм тыгызлыгы;

- Арча муниципаль районының комплекслы социаль-икътисадый үсеш планнары һәм программалары;

- җирле үзидарә органнары һәм кызыксынучы затлар тәкъдимнәрен.

2.6. Җирле нормативлар проекты расланырга кимендә ике ай кала Арча муниципаль районының «Интернет» челтәрендә рәсми сайтында урнаштырылырга һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш.

2.7. Кызыксынучы затлар җирле нормативлар проекты буенча үз тәкъдимнәрен тәкъдим итәргә хокуклы.

2.8. Билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән җирле нормативлар проекты Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре белән килештерелергә тиеш:

- Арча муниципаль районының башкарма комитеты;

- Арча муниципаль районының авыл җирлекләре башкарма комитетлары тарафыннан.

2.9. Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре, әлеге Нигезләмәнең 2.8 өлешендә күрсәтелгән оешмалар һәм ведомстволар белән җирле нормативлар проектын килештерүгә җирле нормативлар проекты җибәрелгән көннән бер ай эчендә килештерәләр.

2.10. Җирле нормативлар проектын килештерү нәтиҗәләре әзерләнгән проектның техник биремгә, норматив техник документларга, Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларына туры килүе турында Арча муниципаль районы башкарма комитеты бәяләмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

2.11. Арча муниципаль районы башкарма комитеты әлеге Нигезләмәнең 2.8 п. күрсәтелгән бәяләмәне әзерләгәннән соң биш көн эчендә Арча

муниципаль районы башлыгының җирле нормативлар проектын Арча муниципаль районы Советы каравына чыгару турында карар кабул итү өчен килештерелгән җирле нормативлар проектын җибәрә.

2.12. Арча муниципаль районы Советы җирле нормативлар проектын раслый. Раслау турындагы карар Арча муниципаль районының "Интернет" челтәрендә рәсми сайтында урнаштырылырга һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә аны кабул иткән көннән алып өч көн эчендә бастырып чыгарылырга тиеш.

2.13. Җирле нормативларны раслау турында карар кабул ителгәннән соң биш көн эчендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты аны Арча муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына тапшыруны тәэмин итә.

2.14. Җирле нормативларны раслау турында карар кабул ителгәннән соң биш көн эчендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты күрсәтелгән карарны, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.1 статьясындагы 2 пункты нигезендә, региональ әһәмияттәге объектлар һәм җирле әһәмияттәге объектлар төрләре буенча шәһәр төзелешен проектлау нормативларын системалаштыруны тәэмин итү өчен, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органына җибәреп тора.

2.15. Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларына үзгәрешләр кертү шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау өчен әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.